**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР
03.06.2020

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПР-111

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең «Яңа Балтач башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» һәм «Кыркаентүбә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» структур бүлекчәләрен бетерү турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, Актаныш муниципаль районының 29.05.2020 нче елгы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссиянең 21 нче бәяләмәсе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Балтач авылы һәм Кыркаентүбә авылы гражданнары җыелышының 22.05.2020 нче елгы беркетмәләре нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәләрен "Яңа Балтач башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе" һәм "Кыркаентүбә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрен 03.06.2020 елдан бетерергә.

2. «Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Ф.А.Гилфановага:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәреш проектын әзерләргә;

- хезмәт законнары нигезендә бетерелә торган мәгариф учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең «Яңа Балтач башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе», "Кыркаентүбә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе" структур бүлекчәләрен закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә бетерергә.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев